**Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 8-9 классов**

1. Саннар артына яшерелгән мәкальне табыгыз (10 б.).
13, 25, 21, 7, 16, 5, 2, 16  23, 1, 24  7, 21, 1, 13  3, 24, 14, 15, 1, 22.
Белемгә карап тай туймас.

2. Фразеологизмнарның бер сүз белән белдерелгән синонимнарын табыгыз (5 б):
*Кул арасына керә башлау* - ярдәм итә башлау;
*Борын салыну* - төшенкелеккә бирелү, әметсезләнү;
*Чыпчык тезеннән* - бик аз;
*Табан ялтырату* - качу, йөгереп качу;
*Борчаклары пешмәү* - уртак тел тапмау.

3. Аваз пропорциясен чишегез (5б.)
Каз : сак = таж : **?** шат

4. Табышмакларның җавабын тап (3 б.):
Күлмәкне икегә аерсак, нәрсә була? кул һәм мәк.
Башы "Т", койрыгы "Н", дошманы "М". Ул нәрсә? тычкан
Тугай кайчан сайрый? „р" хәрефе өстәсә.

5. *Кабыну* сүзенең нинди мәгънәләре бар? Мисаллар белән аңлатыгыз (3 б.).
Караңгы бүлмә яктырып китте, ут кабынгач. Басуда трактор кабынуы авылга ямь бирде. Ачуыннан Марат та түзмәде, кабынып китте. Ялкын кебек кабынам җитә!

6. Тексттагы саннарны сүзләр белән языгыз (10 б)
Бүген дөньяда 6809 алты мең сигез йөз тугыз «тере» тел бар, аларның яртысы сигез илгә: Индонезия, Мексика, Бразилия, Камерун, Һиндстан, Кытай, АКШ һәм Рәсәйгә туры килә. Иң күп телле ил – Һиндстан, аның халкы 845 сигез йөз кырык биш диалектта сөйләшә. Аның артыннан Папуа – Яңа Гвинея килә (монда 600 алты йөз ләп тел бар).

Планетада иң таралган тел булып кытай, инглиз һәм испан телләре санала. Киң кулланыла торган телләрнең беренче унлыгына Пекин диалектындагы кытай теле (бу телдә 875 сигез йөз җитмеш биш млн. кеше сөйләшә), һинди (366 өч йөз алтмыш алты млн), бенгал (207 ике йөз җиде млн), португал (176 йөз җитмеш алты) млн, рус (167 йөз алтмыш җиде млн), япон (125 йөз егерме биш млн), немец (100 млн) һәм корея (78 җитмеш сигез млн) телләре керә.

Бүген дөньядагы телләрнең туксан процентының (аларны йөз меңнән кимрәк кеше генә белә) киләчәге өметле түгел. ә менә бу телләрнең берничә йөзе, гомумән, үлем чигендә тора: әйтик, 357 *өч йөз илле җиде* телдә бүген иллешәр кеше генә сөйләшә, ә 46 *кырык алты* телне, гомумән, берәр кеше генә белә! Галимнәр раславынча, тел яшәсен һәм үссен өчен, бу телдә бер миллионнан артык кеше сөйләшү зарур икән (Матбугаттан).

7. М. Акмулла "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән" дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

*1. 1831 елның 14 декабрендә БР Миякә р-ны Туксанбай авылында туа.*
*2. 2008 елның 8 октябрендә БДПУ каршысында һәйкәл куела.*
*3. 2000 елдан БДПУ Акмулла исемен йөртә.*
*4. Уфада Акмулла өч бүлектән торган арбада йөргән.*
*5. Туксанбайдагы йорт-музейда Акмулла кулы белән җиләнгән урындык бар.*

8. Әсәр белән жанрны тәңгәлләштерегез (5 б):

*1*- Ш.Камал "Акчарлаклар" → комедия *2*
*2*- Г.Камал "Беренче театр" → драма *3*
*3*- М.Фәйзи "Галиябану" → повесть *1*
*4*- Г.Әпсәләмов "Ак чәчәкләр" → роман *4*
*5*- Һ.Такташ "Киләчәккә хатлар" → поэма *5*

9. Билгеләнгән алмашлыклар урынына геройның исемен куегыз (5 б.). Әсәрнең авторын күрсәтегез (2 б.) *Фатих Әмирхан „Хәят" повесте*

....Егетнең йөз кыяфәте һәм сынын тотышы портрет күрсәтүенә караганда, бик сөйкемле иделәр: ачык маңгай, кәкрәебрәк килгән шактый киң кашлар, очлары югарыга каратылып куелган куе вә озын мыек һәм күкрәгсн киерелдеребрәк, егетсымак торыш АҢА *Хәяткә* мәхәббәтле күренделәр.

Егетнең кәләпүшеннән башка бөтен киеме иң соң мода белән Европача тегелгән нәрсәләр иде. Портрет иясе бу яктан да АҢА *Хәяткә* ошады.

УЛ *Хәят* портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты. Шулай карый торгач, бервакыт аңар егетнең кәләпүше артыграк артка киелгән шикелле тоелды да, ул: «Кәләпүшне бераз алгарак киертәсе бар икән» дип уйлады. *(портреттагы егет Г.исәнбердене Самик Фатихов)*

10. Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә күтәрелгән проблемалар (6 б.)

*1. Үткән тормышны, туган нигезне, халыкны онытмау.*
*2. Гореф-гадәтләрне белү, хөрмәт итү, милләтне, телне саклау.*
*3. Ана хакын хаклау, аналарны рәнҗетмәү.*
*4. Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен белү.*

11. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде, дип кайсы әдәби геройны сурәтлиләр? (5 б.) *Әбугалисинаны.*
*(К. Насыйри „Әбугалисина" повесте).*

12. Тексттан микротемаларны билгеләгез (10 б.). Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотыгыз.

Кышлак читендә ялгыз бер өй булган. Биредә Хәлимә исемле кечкенә кызы белән Мәрьям апа яшәгән. Ишегалларында гөлчәчәк куаклары үскән. Ана белән кыз әлеге куакларны бик кадерләгәннәр. Көз килсә, аларны камышлар белән төреп, салкын кыштан яшереп куя торган булганнар. Көннәрдән бер көнне ана белән кыз яңа йортка күчәргә җыенганнар.

– Әнкәй! Безнең гөлчәчәкләребез каламыни? – дип, әнкәсеннән сорап куйган Хәлимә.

– Без күчәсе йортның алдында гөлчәчәкләр күп булса да, боларны да ятим итеп монда калдырмабыз, үзебез белән күчерербез.

Алар ваграк куакларны тамырлары белән казып күчерә алсалар да, иң зур куакка көчләре җитмәгән.

– Кызым, монысы калсын инде. Казый торгач, тамырларын харап итеп ташлавыбыз бар, – дигән әнкәсе.

Кыз, карт куакның үзен генә калдырырга кызганса да, көче җитмәгәч, нишләсен? Шулай итеп алар, иске өйләре алдында карт гөлчәчәк куагын ялгыз калдырып, китеп тә барганнар.

Көз үзе белән салкын җил, кыш рәхимсез суык бураннар алып килгән. Көзге җил дулаган, сызгырган, ыжгырган, әллә кайлардан куе болыт көтүләрен куып китергән дә ялгыз куак өстенә эре-эре тамчыларын сибәргә тотынган. Ә төн җиткәч, кинәт каты суык китереп бәргән. Иртәгесен күкне калын болытлар каплап алган, күбәләк-күбәләк кар яварга тотынган. Мескен карт куак, күз ачып йомганчы, ап-ак кар белән күмелеп калган.

Көн артыннан көн үткән, кояшлы, көләч яз килгән. Үләннәр яшәреп киткәннәр, агачлар чәчәкләргә күмелгәннәр. Бары куак кына язны котлап елмая алмаган. Ул, кышкы суыктан чирләгәнгә, кара янып, тереклектән мәхрүм булып боегып утырган да утырган. Тик кайдадыр, бик тирәндә, тамырларының ерак очларында зәгыйфь кенә тормыш җылысы саклый икән ул.

Ничектер бер көнне Мәрьям апа кызы Хәлимә белән куак яныннан үтеп бара икән. Хәлимәнең күзләре әлеге зур куакка төшкән дә, ул аны кызгануыннан чак кына елап җибәрмәгән.

– Әнкәй! Безнең ялгыз куагыбыз корыган бит, – дип, әнкәсенә сарылган.

– Ай, харап булган шул! – дигән әнкәсе. – Янында агып тора торган арыгы да кибеп беткән икән, ичмасам. Аны тазартып, су җибәрергә кирәк. Бәлкем, шуннан соң яшәреп китәр...

Ана белән кыз арыкны тазартканнар, буасын ачып, аңа саф су агызып киткәннәр.

Чынлап та, кинәт зур куакның тамырларына дым йөгергәне сизелгән. Кечкенә Хәлимә арыкны тикмәгә генә ачмаган бит! Ботакларда беренче бөреләр күренә башлаган, алар күбәйгәннәр, тулыланганнар, ә үзләре барысы да яшәү бөреләре булганнар.

Менә берзаман зур куак янына әнкәсе белән Хәлимә килеп туктаган.

– Әнкәй! Кара әле, куагыбыз чәчәк аткан бит безнең! – дип, кул чабып кычкырып җибәргән Хәлимә. – Арыкка су җибәрүебез бик яхшы булды, әнкәй. Чәчәкләре элеккегә караганда да матуррак!

– Әйе шул! Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган. *(Д.Аппакова)* (398 сүз)

1. Ялгыз өйнең ишегалдында гөлчәчәк куагы үсә.
2. Мәрьям апа кызы белән яңа торакка күчә.
3. Гөлчәчәк куагы кышны ялгызы гына үткәрә.
4. Гөлчәчәк куагы язны көтеп алмаймы, боек.
5. Куакның яңадан чәчәк атуы.

**13. “Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган”,** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Текстта күтәрелгән проблемага туры китереп, эссе языгыз. Фикерләрегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән 2 мисал китерегез.

Язма эшнең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста, төзәтүләрсез һәм танырлык итеп языгыз (25 б.).

Әлеге җөмләне укыгач, „Яхшылык эшлә дә суга сал, балык белер, балык белмәсә Ходай белер," дигән сүзләр искә төшә. Яхшы, файдалы эшләр кешене бизи. Минемчә, Яхшы эшләрең башкаларга да шатлык китерсә, синең үрнәктә калганнар да яхшы эшләргә тартылса, бик зур бәхет ул.

Безнең татар халкы элек-электән тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге белән дан тоткан. Гаиләдә балаларга хезмәт тәрбиясе бирелгән, хезмәткә хөрмәт тәрбияләнгән. Тирә-ягыбызга күз салсак, безне чолгап алган әйберләр – барысы да кемнеңдер хезмәт нәтиҗәсе, хезмәт җимеше.

Минем туган авылымда да хезмәт сөючән, тырыш, уңган кешеләр яши. Мәсәлән, Фидәр Рифат улы һәм аның әтисе Рифат Нәгыйм улы Муллаяновлар. Әлеге нәселнең яхшы эшләре буыннан-буынга да күчә бара. Рифат Нәгыйм улы үзләренең урамына кое эшләгән. Ул коеның суы бик тәмле һәм шифалы. Үзәктән су булмаган вакытларда авылдашлар шул кое суын кулланган. Рифат бабайның безнең арадан киткәненә дә шактый булды. Аның коесы әле бүгенге көндә дә бар, авыл халкын тәмле, шифалы суы.

белән сөйләп тора. Хәзер ул көенең анык улы Флюр абый тәрбияләп, карап тора. Көегә ел җиләксенә юл бар. Флюр абыйның файдалы, изге эшләре авылдашларына гына түгел, республика халкына да таныш. Ел саен үткәрелә торган „Калфак кичләре“н искә төшерсәк тә авылдашыбызның хезмәт нәтиҗәсе күренә. Ул булдырган „Ял паркы“ барлык кеше өчен дә ял урынына әверелде. Теләгән һәр кеше ял итеп, бакчадагы җимешләрдән авыз итеп чыга ала. Әлеге авылдашларыбызның хезмәте күпләрнең күңелендә саклана һәм шатлык китерә.

Әдәби әсәрләрдәге геройлар да тормыштан алына. Һәр әсәр безне, укучыларын, тәрбияли, яхшылыкка өнди. Монда Г. Бәшировның „Намус“ романындагы Нәфисәне, Г. Әпсәләмовның „Ак чәчәкләр“ендәге Әбүзәр абыйны искә төшерми мөмкин түгел. Алар үзләренең хезмәте, яхшы эшләре белән башкаларга шатлык китерә, ышаныч бирә. Үз хезмәтләре нәтиҗәсендә кешеләрнең шатлануын күреп, яңа эшләргә дәртләнгән, юлларындагы киртәләрне үтеп, үрләргә ирешкән әдәби геройларыбыз тормыштан алынган шәхесләр. Без, яшь буынга да яхшы эшләр эшләп, матур нәтиҗәләр белән кешеләргә шатлык өләшеп яшәргә язсын дигән теләктә калам.